ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2024 п.г.т.Алексеевское № 243

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 27.12.2023 ел, №635 «2024 елга Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» 15.12.2023 ел № 867 Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә,

**карар бирәм**:

1. «2024 елга Алексеевск муниципаль районы халкына курсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында» 27.12.2023 ел, № 635 Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- яңа редакциядә «Социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын яллап торучыларга торакны карап тоту өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме» 1 нче кушымтаны (Кушымта) бәян итәргә.

2. Баш мөхәррир Ахманаева Е.Д. га әлеге карарны район газетасында «Заря» (Таң) бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.06.2024 ел, № 243
карарына кушымта

**Социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын яллап торучыларга торакны карап тоту өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме**

| № | Хезмәт исеме | Түләү алына торган хезмәт өчен үлчәү берәмлеге | Хезмәтнең үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (рубльдә) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01. - 30.06. | 01.07. - 31.12. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 3,40 | 3,71 |
| 2 | Йорт яны территориясен санитар карап тоту һәм санитар чистарту | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 2,15 | 4,90 |
| 3 | Торак йортларны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 3,67 | 4,0 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау:<br>-йорт эчендәге санитар-техник челтәрләр<br>- җылыту челтәрләре | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 1,85<br>- | 2,02<br>- |
| 5 | Торак йортларда йорт эчендәге газ челтәрләренә һәм йорт эчендәге газ | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 0,43 | 0,47 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | | | |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 1,09 | 1,19 |
| 7 | Вентиляция каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | - | 0,35 |

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**